**СОВЕТ**
**НОВОШЕШМИНСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯҢА ЧИШМӘ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2022 елның "3" августыннан № 25-192

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2012 елның 28 ноябрендәге 17-131 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 9, 20, 21 статьялары, «Россия Федерациясе җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131 Федераль закон, Яңа Чишмә муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 19 июлендәге 10-53/8613 номерлы уңай бәяләмәсе белән килештерелгән Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү проектына (кушымта буенча) нигезләнеп, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә район Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2012 елның 28 декабрендәге 17-131 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районын территориаль планлаштыру схемасына (Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2013 елның 7 ноябрендәге 28-171 номерлы, 2018 елның 28 декабрендәге 44-258 номерлы карарлары редакциясендә) авыл җирлекләрендә урнашкан генераль планны әзерләү кирәклеге булмау турында карар кабул ителгән түбәндәге торак пунктларның чикләре турында белешмәләр өстәү өлешендә үзгәрешләр кертергә:

1.1. Акъяр авыл җирлегендә урнашкан Акъяр авылы;
1.2. Акбүре авыл җирлегендә урнашкан Сөлчә Баш авылы;
1.3. Архангел авыл җирлегендә урнашкан Архангел Бистәсе авылы;
1.4. Буревестник авыл җирлегендә урнашкан Волчья Бистәсе авылы;
1.5. Екатерина авыл җирлегендә урнашкан Екатерина Бистәсе авылы, Яңа Иванаево авылы;
1.6. Зирекле авыл җирлегендә урнашкан Зирекле авылы, Өргәнче авылы;
1.7. Ленино авыл җирлегендә урнашкан Ленино авылы, Гошково авылы;
1.8. Әдәмсә авыл җирлегендә урнашкан Татар Әдәмсә авылы, Бакташ авылы;
1.9. Чабаксар авыл җирлегендә урнашкан Чуаш Чабаксары авылы, Благодаровка посёлогы, Рус Чабаксары авылы, Татар Әлкин посёлогы;

1.10. Шахмай авыл җирлегендә урнашкан Чаллы Башы авылы, Чертуш авылы.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында(http://novosheshminsk.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга .

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән үзара хезмәттәшлек комиссиясе рәисенә йөкләргә.

Яңа Чишмә
муниципаль районы Башлыгы В. М. Козлов